СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 декабрь Әгерҗе шәһәре № 32-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль норматив хокукый актлар мониторингы нигезендә Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларны тәртипкә салу тәртибе турында Нигезләмә» 2007 елның 12 июлендәге 14-7 номерлы карары;
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә аларның инвестицион программаларын гамәлгә ашыру өчен тарифларга өстәмәләр турында " 2008 елның 25 ноябрендәге 26-5 номерлы карары;
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан социаль ипотека системасында торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен дәүләт яки муниципаль милектә булган җир өлешләрен түләүсез бирү турында Карар кабул итү тәртибе хакында» 2008 елның 28 октябрендәге 25-9 номерлы карары.

2. Әлеге карарны PRAVO.TATARSTAN.RU Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ